КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ
КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ
МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН
САКЛАУ КОМИТЕТЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.05.2023 № 202-П

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2021 елның 12 мартындагы № 50-П боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

1. Татарстан Республикасы Мәдәни мирас объектларын саклау комитетының 2021 елның 12 мартындагы № 50-П боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертүгә) конкурс үткәрү турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.2 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Конкурс дәүләт граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләүгә (алга таба - граждан хезмәте) кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен бәяләүдән, аларның әлеге вазыйфаны биләү өчен башка билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килүен тикшерүдән һәм граждан хезмәте вазыйфасына билгеләп кую өчен кандидатлар арасыннан гражданны (граждан хезмәткәрен) шундый бәяләү һәм тикшерү нәтиҗәләре буенча билгеләүдән гыйбарәт.»;

1.3 пунктының икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Вакантлы вазыйфаны биләүгә конкурс хокукый, кадрлар, мобилизация һәм оештыру эше бүлеге тарафыннан оештырыла.»;

1.4 пунктта «хокукый, оештыру һәм кадрлар эше» сүзләрен «хокукый, кадрлар, мобилизация һәм оештыру эше» сүзләренә алмаштырырга;

1.7 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.7. Конкурс үткәрелмәскә мөмкин:

дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрне кулланып, Комитет боерыгы белән расланган вазыйфалар исемлеге буенча вазыйфаи бурычларны үтәү белән бәйле булган гражданлык хезмәтенең аерым вазыйфаларына билгеләгәндә;

рәис карары белән гражданлык хезмәтенең кече төркеменә керүче гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә;

федераль законнарда каралган башка очракларда.»;

2.4 пунктта:

беренче абзацта «хокукый, оештыру һәм кадрлар эше» сүзләрен «хокукый, кадрлар, мобилизация һәм оештыру эше» сүзләренә алмаштырырга;

икенче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы» сүзләренә алмаштырырга;

2.12 пунктта «хокукый, оештыру һәм кадрлар эше» сүзләрен «хокукый, кадрлар, мобилизация һәм оештыру эше» сүзләренә алмаштырырга;

3.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Граждан (гражданлык хезмәткәре) конкурста катнашуга рөхсәт ителми:

һөнәри белем дәрәҗәсенә, граждан хезмәте стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше буенча эш стажына квалификация таләпләренә туры килмәве сәбәпле;

аның белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә (белгечлекләрнең һәм әзерлек юнәлешләренең берләштерелгән төркемнәренә) квалификация таләпләренә туры килмәвенә, һөнәри әзерлек буенча өстәмә һөнәри программаны үзләштерү нәтиҗәләре буенча алынган квалификациягә (граждан хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен квалификация таләпләре мондый таләпләр каралган очракта);

граждан хезмәтенә керүгә һәм аны узуга һәм дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләүләргә бәйле рәвештә.»;

3.4нче пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«мәгариф һәм (яисә) квалификация турындагы документларның күчермәләре, шулай ук гражданның теләге буенча фәнни дәрәҗә бирү турындагы документларның, гыйльми исем бирү турындагы документларның нотариаль яисә хезмәт (эш) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәләре;»;

4.2 пунктта «хокукый, оештыру һәм кадрлар эше» сүзләрен «хокукый, кадрлар, мобилизация һәм оештыру эше» сүзләренә алмаштырырга;

4.5 пунктта:

беренче абзацта «хокукый, оештыру һәм кадрлар эше» сүзләрен «хокукый, кадрлар, мобилизация һәм оештыру эше» сүзләренә алмаштырырга;

4.5 нче пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданның (граждан хезмәткәренең) квалификация таләпләренә һөнәри белем дәрәҗәсенә, граждан хезмәте стажына яисә белгечлек, әзерлек юнәлеше, һөнәри дәрәҗәгә карата, шулай ук яллаучы вәкиленең тиешле карары булганда - белгечлеккә, әзерлек юнәлешенә (белгечлекләрнең һәм әзерлек юнәлешләренең берләштерелгән төркемнәренә), һөнәри әзерлек буенча өстәмә һөнәри программаны үзләштерү нәтиҗәләре буенча алынган квалификациягә туры килүен тикшерү.»

4.10 пунктының икенче абзацында «хокукый, оештыру һәм кадрлар эше» сүзләрен «хокукый, кадрлар, мобилизация һәм оештыру эше» сүзләренә алмаштырырга;

пункт 4.12 изложить в следующей редакции:

«4.12. Конкурс уздырганда конкурс комиссиясе кандидатларны алар биргән белем турында һәм (яисә) квалификация турында документлар нигезендә, граждан яисә башка дәүләт хезмәтен узу, башка хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашыру, шулай ук, федераль законнарга һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына һөнәри дәрәҗәне, кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү ысулларын кулланып, конкурс процедуралары нәтиҗәләре нигезендә, тестлауны, анкеталаштыруны, индивидуаль әңгәмәне, реферат яки башка язма эшләр язуны да кертеп, документ проектын әзерләүне дә кертеп, бәяли. Конкурс уздырыла торган вазыйфалар төркеменә һәм категориясенә карап, төрле ысуллар

кулланыла ала. Шул ук вакытта кандидат белән тест үткәрү һәм индивидуаль әңгәмә барлык кандидатлар өчен мәҗбүри методлар булып тора.

Кандидатларның һөнәри дәрәҗәсен, һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләгәндә конкурс комиссиясе гражданлык хезмәтенең вакантлы вазыйфасын биләү өчен тиешле квалификация таләпләреннән һәм әлеге вазыйфа буенча вазыйфаи регламентның башка нигезләмәләреннән, шулай ук дәүләт граждан хезмәте турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән башка нигезләмәләрдән чыгып эш итә.

Комитет тарафыннан конкурс комиссиясе эшчәнлеге өчен, шулай ук кандидатлар тарафыннан конкурс процедураларын узу өчен тиешле оештыру һәм матди-техник шартлар төзелә.»;

4.12.1 пунктта:

икенче абзацта «Татарстан Республикасы Президенты каршындагы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы» сүзләренә алмаштырырга;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тест үткәрү Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты тарафыннан раслана торган тест үткәрү методикасы нигезендә гамәлгә ашырыла»;

4.12.6 пунктының өченче абзацында «хокукый, оештыру һәм кадрлар эше» сүзләрен «хокукый, кадрлар, мобилизация һәм оештыру эше» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге боерыкның гамәле 2023 елның 29 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Комитет рәисе И.Н. Гущин